СОВЕТ
ЧУВАШСКО-ДРОЖЖАНОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Улица Октябрьская, дом 21а,
Село Чувашское Дрожжаное, 422485

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЧУАШ ЧҮПРӘЛЕСЕ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

Октябрь урамы,21нче йорт,
Чуаш Чүпрәлесе авылы,422485

Тел.: 8(84375)3-72-48, 8(84375)3-72-23, факс: 8(84375)3-72-48, Chuvd.Drz@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

11.02.2019 ел №40/1

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

"Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында" гы 02.03.2007 ел № 25-ФЗ Федераль законга, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Чуаш Чүпрәле авыл җирлеге Уставының 29 матдәсенә туры китереп, Чүпрәле районы прокурорының 16.01.2019 ел протестын исәпкә алып, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Чуаш Чүпрәле җирлеге 23.10.2008 ел № 39/1 Карары белән расланган Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Чуаш Чүпрәле авыл җирлеге хезмәт турындагы нигезләмәнең ( 13.04.2009 №46/2, 25.05.2009 № 47/2, 01.06.2013 № 29/1, 03.04.2014 № 40/2, 10.08.2015 № 55/2, 16.07.2015 № 51/2, 08.04.2016 № 8/5, 31.01.2017 № 14/5, 29.06.2017 № 18/2, 04.10.2017 № 20/3 редакцияләрендә) 3 бүлегенең 3.2 өлешенә, түбәндәге эчтәлектәге 3.2.7-3.2.8 пунктларын өстәп, үзгәрешләр кертергә:

«3.2.7. Район Советы Рәисе, Район Башлыгы, Башкарма комитет Җитәкчесе, Район территориясендә урнашкан суд һәм хокук саклау органнары җитәкчеләре белән якын туганлыгы яки туганлык үзлекләре (ата-анасы, ире яки хатыны, баласы, ир туганнары, кыз туганнары, шулай ук ире яки хатынының ир туганнары, кыз туганнары, ата-анасы, баласы һәм балаларының ире яки хатыны) булган очракларда граждан контроль-хисап органы рәисе, рәисе урынбасары һәм аудиторы вазифаларына билгеләнә алмый, ә муниципаль хезмәткәр контроль-хисап органы рәисе, рәисе урынбасары һәм аудиторы вазифаларын били алмый.

3.2.8. Җитәкче булган муниципаль хезмәткәр, Районның җирле үзидарә органында, сайлау комиссиясе аппаратында мәнфәгатьләр конфликтын

булдырмау максатында, күрсәтелгән вазифаны биләгән чорда Районның шушы җирле үзидарә органының, сайлау комиссиясе аппаратының сайланып куелган профсоюз органында муниципаль хезмәткәрләр мәнфәгатьләрен яклый алмый.».

2. Әлеге Карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

1. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үзем артыннан калдырам.

Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль районы
Чуаш Чүпрәле авыл җирлеге башлыгы: В.В.Землемеров